**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» март 2020 ел № 85

«НК-Геология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Тымытык нефть ятмаларын төзекләндерү» проектының планлаштыру проекты составында линия объектларына Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге чикләрендә территорияне планлаштыру һәм межалау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә, «Геомониторинг» ҖЧҖ тәкъдимен карап, территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линияле объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатыннан, карар итә:

1. «Геомониторинг» җавыплылгы чикләнгән җәмгыятенең үз акчалары хисабына «НК-Геология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Тымытык нефть ятмаларын төзекләндерү» проектының планлаштыру проекты составында линия объектларына Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге чикләрендә территорияне планлаштыру һәм межалау проектын әзерләү тәкъдимен кабул итәргә.

2. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау өчен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә юлларга. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турындагы тәкъдимнәрне караганда әлеге тәкъдимнәрне керткән физик һәм юридик затларны чакыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
инфраструктура буенча җитәкче урынбасары Р.Р. Ханнанов